**Хәким, З.  Ана җыры: роман** / З. Хәким // Казан утлары. – 2020. – №6 (1172). – Б. 3-80

…Әмма аның иң зур хыялы, монда килүенең төп максаты – үзенең кем, кайдан булуын, ата-анасы кемнәр икәнне белү һәм әнисенең язмышын ачыклау иде. Ник баласын ташлап качты икән ул? Үзе исән микән? Исән булса, кайларда икән хәзер?...




"Казан утлары" журналының 6 санында (2020 ел) Зөлфәт Хәкимнең - татар халкының мәшһүр җырчысы, композиторы, драматургы, җәмәгать эшлеклесенең "Ана җыры" романы басылды. Әсәрнең темасы татар теле, татар җыры, татар тарихы, татар җирлеге, татар дәүләтчелеге, милләтебезнең киләчәге, бүгенгесе, үткәне белән бәйле. Роман маҗаралы-мавыктыргыч сюжетка корылган. Әсәрнең төп герое – 3 яшендә "югалган" ятим малай Рахман – әнисен эзли. Әмма төп эзләгән кыйммәт – Рахманның әнисе генә түгел. Герой белән бергә без татар милләтенең үзаңын тәшкил итә торган асыл баганаларны эзлибез.